ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

с. Большие Меми

20.09.2016 № 3

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Олы Мәми авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Олы Меми авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрүнең уртак инициативасын тәкъдим итергә:

«Сез 2017 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә ризамы?:

- Олы Меми авылы территориясендә урнашкан зиратка кадәр вак таш түшәлгән керү юлы төзелеше

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г. А. Фомина